РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2019 № 1028

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Нурлат муниципаль районы бюджетыннан Нурлат муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, Нурлат муниципаль районы бюджетыннан Нурлат муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2019 ел, 18 ноябрь, 1028 нче карары белән расланды

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Нурлат муниципаль районы бюджетыннан Нурлат муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләре

1. Нурлат муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Нурлат муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен (алга таба – субсидияләр) финанслашу максатларында бирелә.

2. Субсидияләр Нурлат муниципаль районы Советының «Нурлат муниципаль районының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджеты турында»гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүчесе булып Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты санала.

4. Финанслашу максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан, Нурлат муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә торган субсидия күләме, шул исәптән аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә субсидияләрне бүлү Нурлат муниципаль районы Советының «Нурлат муниципаль районының 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 елларның планлы чорына бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм тәртибе Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Нурлат муниципаль районы җирлекләре Башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен контрольдә тоту тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыру сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Нурлат муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Нурлат муниципаль районы җирлегенең җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен килешүдә билгеләнгән срокларда ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетларына Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан җирлекләр бюджетларына субсидияләр күчерелә.

13. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Нурлат районы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

15. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын закон нигезендә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты һәм «Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы»муниципаль казна учреждениесе контрольдә тота.